# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы<br>Дәүләт Советы тарафыннан<br>2012 елның 21 июнендә<br>кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 8.1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); Ватаным Татарстан, 2012, 17 гыйнвар, 20 июнь) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле яңа унынчы өлеш өстәргә:
"Әлеге статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 3.6 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасының Экология һәм табигать байлыклары министрлыгының вазыйфаи затлары Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге норматив хокукый актлары белән билгеләнгән вәкаләтләрне башкарганда төзергә хокуклы.";

2) унынчы өлешне унберенче өлеш дип санарга һәм "алтынчы" сүзеннән соң ", унынчы" сүзен өстәргә;

3) унберенче өлешне уникенче өлеш дип санарга;

4) уникенче өлешне унөченче өлеш дип санарга һәм анда "тугызынчы" сүзен "унберенче" сүзенә алмаштырырга;

5) унөченче өлешне ундүртенче өлеш дип санарга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 14 июле
№ 50-ТРЗ